| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 октябрь г.Казань № 901

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 ел, 27 февраль, 129 нчы карары белән расланган «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 ел, 27 февраль, 129 нчы карары белән расланган «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4.2 пунктта:

2.4.2.1 – 2.4.2.3 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.2.1. Үлчәү һәм габарит контроле чараларын, шул исәптән автоматлаштырылган системалар ярдәмендә (алга таба – АСВГК) инструменталь һәм программа белән тәэмин итү, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә норматив хокукый актлар үтәлешенә дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча бирелгән вәкаләтләр кысаларында Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт йөртүчеләрнең барлык төркемнәренә карата вәкаләтле контроль-күзәтчелек органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла;

2.4.2.2. 3,5 һәм 12 тоннадан артык рөхсәт ителгән транспорт чараларыннан түләү алу системаларын гамәлгә кертү һәм төзү, шулай ук Татарстан Республикасы-

ның төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында йөрү турында мәгълүматларны җыю, эшкәртү, саклау һәм автомат режимда тапшыру;

2.4.2.3. Автомобиль юлларына авыр авыр йөк транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау хисабына түләү хисапларын уздыру;»;

2.4.2.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.2.5. Татарстан Республикасының автомобиль юллары буйлап, шул исәптән бирелгән вәкаләтләр кысаларында автомобиль юлларында хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында, авыр йөк һәм (яки) зур габаритлы транспорт чаралары хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү, шул исәптән электрон формада.

«Бер тәрәзә» принцибы буенча Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авыр йөк һәм (яки) зур габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә электрон формада махсус рөхсәт бирү буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү (электрон рәвештә хезмәт күрсәтү) системаларын эшләү;»;

2.4.13 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.4.13.1 һәм 2.4.13.2 пунктчалар өстәргә:

«2.4.13.1. Транспорт чараларын ташу буенча махсуслаштырылган автомобиль транспорты эшчәнлеге. Автотранспорт чаралары, велосипедлар өчен стоянкалар, гаражлар, машина кую урыннары эксплуатацияләү, транспорт чараларын саклау;

2.4.13.2. Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерүне оештыру, аларны саклау, кире кайтару, күчерү һәм саклау бәясен түләү;»;

2.4.27 һәм 2.4.28 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.27. Учреждение эшчәнлеген тормышка ашыру, хокук саклау юнәлешендәге программаларны (чараларны) тормышка ашыру, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өчен кирәкле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә сатып алуларны башкару;

2.4.28. Тәэминатчы, подрядчы, башкаручы буларак чыгыш ясап, төзелгән контрактлар (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү очракларында товарлар китерүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә сатып алуларны гамәлгә ашыру;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин